Сигал) һәм «Татара – Евразия мирасы» проекцияле хореографик шоуы (куючы режиссер Туфан Имаметдинов (2020), куючы режиссер Катцуми Сакакура (2021)) алынды. Тикшерү предметы – *тимерче-самурай* һәм *татара* миче образлары. Мәкаләдә *татара* уникаль технологиясенең өйрәнелү дәрәҗәсе һәм Япониядә шул исемдә сакланып калган мич турындагы мәгълүматлар төрки-япон элемтәләре яктылыгында системага салына. Әлеге теманың Япония һәм Татарстан Республикасының мәдәният әһелләре тарафыннан сәнгати шәрехләнүе ягыннан үзенчәлекләре ачыклана. Ёсинари Насикори, Сакакура Кацуми, Туфан Имаметдинов, Сөмбел Гаффарова эпик геройның сөеклесен коткару өчен аждаһа белән көрәш сюжетын коралар. Инициация төп сюжет булып әверелә. Мәхәббәт сюжеты ярдәмче рольне уйный. Япон һәм татар сценаристлары игътибарны баш геройның эчке каршылыгы үзенчәлекләрен ачуга юнәлтә. Режиссер Ёсинари Насикори милли эчтәлекне чынбарлыктагыча бирүгә омтылыш ясаса, куючы режиссерлар Сакакура Кацуми белән Туфан Имаметдинов стильләштерүгә күбкрәк йөз тота.

Проекцияле шоуның татарча варианты – формасы ягыннан экияти-фантастик гомумиләштерүгә, япон вариантының символик формасы мифлаштыруга йөз тота. «Кылыч туганда» документаль фильмы мәгърифәтчел-агарту характерына ия.

**Төп төшенчәләр:** Япония, Татарстан Республикасы, мәдәни элемтәләр, Ёсинари Насикори, Сакакура Кацуми, Туфан Имаметдинов, *татара* миче*,* тимерче-самурай

## Кереш

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының элекке директоры Рафаэль Хәкимов хатирәләрендә язылганча, Татарстан Республикасы президенты Рөстәм Миңнеханов 2015 елда Япониягә баргач, металл эретүнең «татара» дигән технологиясе турында, «татар адымы», «татар көрәше» турында бик күп мактаулы сүзләр ишетеп кайта. Әлеге мәсьәләне тирәнрәк өйрәнү өчен, Татарстаннан фәнни делегация Япониягә оча. Икеяклы әлеге очрашу 2015 елда Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты белән Симанэ Университетының Төньяк-Көнчыгыш Азияне өйрәнү үзәге арасында фәнни хезмәттәшлек итү турында килешү белән тәмамлана, аның кысаларында ике халыкның матди мәдәнияте тарихын өйрәнү башлана.

2015 елдан башлап, берничә фәнни конференция үткәрелә, аларның эшендә үзебезнең ил галимнәре белән беррәттән чит илләрдән металлургия тарихы буенча Др. Нориюки Какуда (Идзюмо тарих музее), Др Вэньсуо Лю (Сунь Ятсен университеты, КХР), Марселла Феста (Ка-Фоскари университеты, Венеция, Италия), Др. Ясуки Мураками (Борынгы көнчыгыш Азия тимер мәдәниятен өйрәнү үзәге, Эхиме университеты) кебек танылган белгечләр катнаша ([1], [2], [3]).

А. Е. Лестнев фикеренчә, «тимер рудасын *татара* мичен кулланып эретүнең Япониядә сакланып калган традицион ысулы өйрәнү, яңадан торгызу, тимер эретүнең һәм Евразия халыкларының корал җитештерү буенча тарихи традицияләрен кайтару өчен мөһим чыганак булып тора» [3, 247 б.]. Казан галиме традицион корал җитештерү методларын торгызу өчен, бу теманы өйрәнү перспективасына ышана [3, 250 б.].

Мураками Ясуюки үзенең хезмәтендә японнарның тимер эретү «татара» традицион технологиясенең прототибы безнең эраның VI гасырында ук формалашуы турында ышандырырлык дәлилләр китерә. Япон галиме әлеге технология Көнбатыш Япониядә (Чугоку төбәге) XVII гасырга формалашып бетә дип саный. Мураками Ясуюки Япония белән Корея ярымутравы арасында технологик элемтәләрнең булуы турындагы гипотезага да ишарә итә [3, 238–240 б.]).

А. Е. Лестнев «татара» ысулы VII–VIII гасырларда барлыкка килгән дигән караштатора. Галим Япониядә тимерчелек һөнәренең үсешендә Кытай традициясенең аерым бер роль уйнавына да игътибар итә [3, 246–247 б.].

Япон галиме Ма Мин Да үзенең фехтование өлкәсендә кытай-япон-корея тәҗрибәләре алмашын өйрәнүгә багышланган фундаменталь хезмәтендә дао һәм цзянь кылычларының төрләре безнең эраның III гасырыннан башлап Кытайдан Япониягә китерелә торган төп товар булуын яза. VIII гасырга Кояш чыгышы илендә кылыч кою сәнгате шул дәрәҗәдә югары була ки, аларны Кытайдан китерү ихтыяҗы тәмам юкка чыга. X гасырдан Кытайга инде япон кылычлары кертелә башлый (тулырак моннан карагыз: [4]).

Кояш чыгышы иленең топонимикасын өйрәнгән тел галиме Валерий Курбатов шундый нәтиҗәгә килә: борынгы заманнарда төркиләр Япониядә булган. «Аоморе белән

Хатинохе шәһәрләре арасында Хонсю утравының төньяктагы түбән өлешендә Tatara yama (япончадан: тау) һәм Tatarasan (*san* кисәкчәсе кешеләргә карата ихтирамлы эндәшүне аңлата; бу очракта тауга карата әйтелә. Күрәсең, тауны җанландыру яисә тау рухына карата мөнәсәбәтне чагылдыра) бар (Карта №1). Токиодан төньякка таба (Тиба перфектурасы) билгесез гидронимга карый торган Tataranuma (япончадан *саз* дигәнне аңлата, *сазлы урын*) утраучыгы бар. Утрауның көньяк ярында Убе шәһәреннән төньяккарак Tatarasaki күле урнашкан. Бу серия Рюкю күленең көнбатышында үзенчәлекле трио, ике утрау һәм *Tatarashima* тавы (япончадан *утрау*), шулай ук Tatara *gawa* (япончадан *елга*) белән тәмамлана» [5, с. 12]. Үзенең мәкаләсендә галим шулай ук төркиләрнең Япониядәге фаразланган маршрутының гипотезасы белән уртаклаша: «Амур яныннан Сахалинга, аннан соң Япониягә чыкканнар. Шул ук вакытта, күренгәнчә, Хоккайдо утравын көнчыгыштан яки көнбатыштан әйләнеп узганнар. Хонсю утравының төньяктагы түбән өлешендә Огавара күле янында Нобедзи җирлегенә килеп төшкәннәр. Шушы урыннан яр буйлап яки Китаками елгасы үзәне аша Тоне елгасына кадәр барып җиткәннәр. Алга таба эзләр утрауның көнбатыш ягында күренә, башта Кисо елгасы буйлап өскә таба Бива күле һәм Хида калкулыгы арасыннан күтәреләләр. «Татар» топонимнары Кюсю утравында тәмамлана, аны Корея ярымутравы аша Амноккаи елгасына кадәр узган «*казан*» исемен йөртүчеләр калдырып китә. Биредә хәрәкәт туктала. *Kazan* култыгыннан япон лоцманнары бу атаманы көньяк утрауларга һәм Кытай ярларына алып килә [5, 12 б.].

Галимнең гипотезалары Дж. Киддерның «Буддизмга кадәрге Япония» дигән китабында да раслау таба. Әлеге тикшеренүче япон кенәзләре, безнең эра башында утрауга төрки күчмә халыклары бәреп кергәч кенә, атка атланып йөри һәм ырудашларын курганнарда җирли башлый дип саный: төркиләр аларны кавалерия күнекмәләренә өйрәтә һәм эсхатология өлкәсендә күзаллауларын үзгәртә [6].

В. Курбатов «читтән килүчеләрнең борынгы япон җәмгыятенә үтеп керүе шактый тирән булган” дигән фикерне ассызыклый [5, 13 б.]. Мөһаҗирлек юнәлешләре һәм Кореядән кергән «*tatara*» технологиясен тапшыру арасындагы каршылыклы фикерләр турында уйланып, галим биредә сүз гади төркиләр турында түгел, ә һинд-европа йогынтысына бирешкән борынгы төркиләр турында бара дип саный. Утрауларга килгәндә, төркиләр инде «тимер җитештерүнең примитив технологияләренә ия булган һәм аны «кояш чыгышы» һәм «иртәнге саф һава» илендә тараткан». Сәяхәт ахырына алар бу технологияләрен камилләштергәннәр һәм күпкатлы корыч җитештерү ысулын да тапканнар – самурайлар аны үзләренә катана кылычлары кою өчен үзләштергәннәр» [5, 13 б.]. Тел галиме фикеренчә, төркиләрнең Алтайдан кузгалуы безнең эрага кадәрге меңьеллыкның урталарыннан да иртәрәк булмаган [7, 360 б.]. «Төркиләр алтайдан чыккан дип исәпләнә. Без алдан билгеләп үткәнчә, безнең эраның беренче меңьеллыгының икенче яртысында көнчыгышка таба юл тоткан булсалар, алар тимерне кельтлар (Латен мәдәнияте, безнең эрага кадәр 5-1 гасырлар) белән бер вакытта эшкәртә башлаган, шул ук вакытта төркиләр аны һинд-европалылардан – бронза мәдәниятен йөртүче “андронлылар”дан ала алмаган», – дип раслый үзенең тикшеренүләрендә В. Курбатов [5, 13 б.].

Р. Хәкимов «*татара*» технологиясен утрауга татарлар алып килгән дип саный. Галим карашынча, «*татара*» технологиясе примитив быргыдан зур күләмдә металл эретүнең катлаулы системаларына кадәр этаплар үтә. Археология мәгълүматларына караганда, беренче примитив формасы Хакасиядә очрый. Алтай, Хакасия, Тыва, Минусин чокыры борынгы заманнардан металл җитештерү белән дан тота. Хакасиядә сакланып калган археология һәйкәлләре һава өрдерү өчен икешәр мехлы быргылар булганлыгы турында сөйли, Япониядәге «*tatara*»ның беренче үрнәкләре дә якынча шундый булган. Алга таба японнар әлеге технологияне үстерәләр, шул рәвешле металл эретү күләмнәрен арттыру мөмкинлеге барлыкка килә» (тулырак карагыз: [8]).

**Тикшеренүнең материаллары һәм ысуллары**

Безнең тикшеренүнең объекты булып «Tatara Samurai» («Тимерче-самурай», режиссеры Ёсинари Насикори, 2016) нәфис фильмы, «Кылыч туганда» документаль фильмы («Самурайлар. Сугыш сәнгате» күргәзмә проекты (продюсер Георгий Аистов, кураторы Стивен Сигал, 2016) һәм «Татара – Евразия мирасы» дигән проекцияле хореографик шоуы (куючы режиссер Туфан Имаметдинов (2020), куючы режиссер Катцуми Сакакура (2021)) тора.

Тикшеренүнең предметы – *тимерче-самурай* һәм *татара* миче образлары.

Хезмәт гомумфәнни һәм махсус фәнни ысуллар нигезендә язылды: анализ, синтез, аналогия, чагыштыру, янәшә кую, уйлап чыгарылган һәм чынбарлык, дөреслек һәм дөреслеккә охшаш, автор һәм герой проблемалары белән бәйле кайбер теоретик нигезләмәләргә төгәллек кертү мөмкинлеге биргән типлаштыру.

**Фикер алышу**

Бүгенге көндә *татара* мичендәге ялкын дөньяда бер генә урында – Япониянең Симанэ префектурасында дөрли. Әлеге мич Япониянең мәдәни мирасы исемлегенә кертелгән. Бүген Япония һәм Татарстан Республикасы әлеге мәдәни объектны ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объектлары исемлегенә кертү белән шөгыльләнә. Тарихчыларның тикшеренүләре кайбер мәдәният әһелләрен шушы могҗизалы артефакт һәм уникаль технология турында сөйли торган кызыклы мәдәни проектлар тудырырга илһамландырган. 2016 елда япон режиссеры Ёсинари Насикори «Tatara Samurai» («Тимерче-самурай») дигән нәфис фильм төшерә, анда *татара* миче сакральләштерелә һәм тутыкмый торган уникаль корыч җитештерүче тимерчеләр династиясенең хезмәтенә дан җырлана. Монреальдә узган 40 нчы Халыкара кино фестивалендә әлеге фильм иң яхшы артист эше өчен бүләккә лаек була. 2020-2021 елларда Казанда «Татара – Евразия мирасы» проекцияле хореографик шоуының (режиссеры Туфан Имаметдинов) татар һәм япон версияләренең премьералары уза. Бу – Япониянең Россиядәге илчелеге белән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы арасындагы тыгыз хезмәттәшлек нәтиҗәсендә барлыкка килгән уртак проект. Тасвирлы шоуда тимерченең сөйгән кызын коткару өчен кылган батырлыгына дан җырлана. Сценарий авторы – драматург Сөмбел Гаффарова. Шоуда эпик геройның корал табуына мөһим урын бирелә. *Татара* миче, бер яктан, шоуда традицион рухта бирелә: тамашачылар уникаль корыч тууының һәм аннан кылыч ясауның илаһи мизгелләре шаһиты була, икенче яктан, әлеге артефакт эпик геройның кәләшен әсирлектә тотучы аждаһа яшәгән урынга әйләнә.

Самурайлар турындагы кино традицияләре кысаларында «Tatara Samurai» («Тимерче-самурай») картинасында вакыйгалар XVI гасырда Япониянең көнбатышында урнашкан һәм *татара* тимерен эшкәртү буенча борынгы технологияләре белән дан тоткан бер авылда бара. Картинаның баш герое Госукэ исемле яшь тимерче, аңа язмыш тарафыннан алдынгы мураги тимерчеләр династиясен дәвам иттерү язылган. Безнең алда үз юлын эзләүче герой. Алдан күрүчән әбисе сүзләренә карaганда, аның оныгы самурай булгач, язмышына каршы барырга кара кыла. Геройны моңа фаҗигале хәлләр мәҗбүр итә. Госукэ туган авылын юлбасарлар һөҗүмнәреннән саклау турында хыяллана, югыйсә коралсыз хезмәт кешеләре бер гаепсезгә һәлак була. Ул Ода Нобунаги әфәнде армиясенә языла, ул анда кухняда хезмәт итә. Беренче тапкыр хәрби хәрәкәтләр уртасында калгач, Госукэ чын мәгънәсендә тетрәнү кичерә: кайчандыр крестьяннар уңыш алабыз дип утырткан кырлар үлем кырына әйләнә. Тимерче хәзерге заманда алып барыла торган сугышларның ни дәрәҗәдә үзгәрүен үз күзләре белән күрә. Хәзер самурайның намуслылыгы һәм аның уникаль кылыч белән көрәш сәнгате түгел, ә астыртын рәвештә ата торган мылтыкларның саны хәлиткеч роль уйный. Канкойгыч бәрелештә исән калып, Госукэ өенә кайта, анда ул туган авылын, утлы корал эшләү өчен, уникаль корыч турында хыялланган аучылардан сакларга мәҗбүр була. Көч куллануга эстетик мәгънә салмау «Tatara Samurai» фильмын төшерүчеләрнең төп казанышы булып тора. Картинада самурай романтизмы традицияләре өстенлек итә. Сугыш күренешләре ничек кенә чынбарлыкка якын итеп төшерелмәсен, аларда кан елга булып акмый, аяк-куллар өзелеп, тирә-якка очмый. Се Аоянагиның герое самурай картиналары һәм японнарның сугыш турындагы киноларындагыча рәхимсез самурайларга бөтенләй охшамаган. Ул табигать ритмына буйсынып яшәргә омтыла. Аның ыруы вәкилләре корыч җитештерүнең уникаль технологиясе аларга бүләк итеп бирелгән һәм сакраль рәвештә хезмәт итүне таләп итә дип саный: «Күмер, җир, тимер комы, ут, су, үлән, җил. Кеше барысын да үзе тудыра алмый... Татара – Табигатьнең бөек бүләге».

Карт күмерче (Масахико Цугава) яшь тимерчегә авыл җәмгыятендә тотрыклылык гаранты булган эчке иерархияне күрсәтә. Технологиянең үлемсезлеге авылда тимерчеләрнең һәм агач күмерчеләренең гаилә династияләрен тәэмин итә. Җитештерелә торган корычның сыйфаты турыдан-туры

мурагиның рухи халәтенә бәйле, ул шулай ук корыч җитештерүне оештыру өчен дә җавап бирә. Карт күмерче яшь тимерчегә үзенең тәкъдиренә ышанырга киңәш итә: мураги күнекмәләренә өйрәнер һәм технологияне мирас итеп тапшырыр өчен, әтисенең ничек эшләвен күзәтергә куша. Мураги технология-нең саклануы өчен генә түгел, авылдагы тормыш-көнкүрешнең барышы өчен дә җавап бирә.

Фильмда *татара* уникаль корычын җитештерүнең барлык технологик процесслары җентекле тасвирлана. Тимерченең хезмәте мифлаштырыла, иҗат акты буларак манифест рәвешендә тәкъдим ителә. Туган ягыннан аерылып торганда, Госукэ Идзумоның сакраль кыйммәтенә төшенә. *Татара* мичен сакральләштерүдә һөнәрчеләрнең коллектив җыры мөһим роль уйный: *«Яшел таулар аша җилләр исә, / Агачлар, ут, җир ул якларда – / Бөек Табигатьнең рәхмәте, / Татара корычы акча алып килә, / Изумо төбәгендә муллык корычы»*. Бу грекларның Олимпы кебек үк изге ил, анда Кояш алиһәсе Аматерасу, Җил алласы – Сусаноо, Җир алласы Окинуси-но микото, Нинигu алласы бар.

Тора-бара баш герой үзенең *татара*га хезмәт итүенең мәгънәсенә төшенә. Бөек Табигатьнең бүләге адәм баласының кабахәт-леген, рух йомшаклыгын, комсызлыгын, мәгънәсез рәхимсезлеген кабул итми. Госукэ кулындагы кылыч җирнең хакимлек (мураги юлына баскан герой ыруның яшәве, уникаль технологиянең саклануы өчен җаваплылыкны үз кулларына ала), илаһи чисталык (Госукэ бөтен кеше күз алдында комсызлык символы булган мылтыкны юк итә), батырлык, самурай намусы (яшь тимерче бер тапкыр да кеше гомерен кыймый) билгесенә әверелә. Фильм ахырында герой үзендәге каршылыкны җиңә: язмышына буйсына һәм мураги була.

«Сакура» татар-япон мәдәни-мәгълүмати үзәге җитәкчесе Асия Садыйкова башлангычы белән барлыкка килгән «Татара – Евразия мирасы» проекцияле шоуы ике дәүләтнең иҗат коллективлары ярдәмендә гамәлгә ашырыла. Проектның кураторы Сакакура Катцуми – тере проекцияле шоу жанрын тудыручы булып тора, бу жанр кысаларында биюче видеорәтнең дәвамы булып аңлашыла. Премьераның япон версиясеннән соң тәэссоратлары белән бүлешкәндә, куючы режиссер балачактан ук җитди рәвештә каратэ белән шөгыльләнүе турында әйтте. Фикердәшләре белән бергәләп, японнарның традицион мәдәниятен өйрәнгәндә, аның уникальлегенә төшенеп, алар каратэ ритмын биюдә кулланырга булалар. Бу исә аларны биюнең үзенчәлекле стилен тудыруга китерә. «ORIENTARHYTHM» төркеменең оригиналь бию стиле ярдәмендә Сакакура Кацуми һәм аның ярдәмчеләре «Japanese Cool» биюен бөтен дөньяга тәкъдим итә. Аларның биюле чыгышларының һәм проекцияле перформансларының бер максаты – япон мәдәниятенә кызыксыну формалаштыру. «Татара – Евразия мирасы» проекцияле шоуының уникальлеге япон мәдәниятенә хас булган ритм, рух көче һәм хәрәкәтнең гармонияле тәңгәллегеннән гыйбарәт.

Пандемия сәбәпле, Япония белән Татарстанның иҗат әһелләренә коллектив шоу тудыру мөмкин булмый. Алар татар драматургы Сөмбел Гаффарованың фантазиясе тудырган әкияти тарихны гәүдәләндергән ике мөстәкыйль шоу әзерләргә мәҗбүр була.

Шоуның татар версиясен режиссер Туфан Имаметдинов куя. Видеоконтентны «ImpressIM» студиясе (җитәкчесе Дамир Алләмов) әзерли. Шоуның музыкаль бизәлеше өчен Фәрит Гарипов, Руслан Габитов һәм «Риваять» этнотөркеме җавап бирә. Татар версиясендә биючеләр Марсель һәм Мария Нуриевлар, Софья Слинченко катнаша. Катцуми Сакакура җитәкчелегендәге япон версиясендә Эйко Иваки, Мами Миямото, Карин Кото катнаша.

С. Гаффарованың сценарие еланга каршы көрәшкә чыккан батыр турындагы әкияти сюжетка корылган. «Зыян» салучы ролендә – сигез башлы аждаһа, ул батырның илен туздыра һәм аның сөйгәнен әсирлеккә ала. Бу сюжет тамырлары белән Кабуки япон театрының нигезен тәшкил иткән борынгы риваятьләргә барып тоташа. Татар драматургы эпик геройдан, сөйгәнен коткару өчен, юлга чыгуны таләп иткән өйләнү тарихын үстерә. С. Гаффарова күрәзәле төш мотивын уңышлы куллана [9]. Юлда Батыр дүрт ярдәмче – табигать көчләре белән очраша: Җир, Су, Һава, Ут. Алар геройга көч бирәләр һәм тылсымлы коралны кулга төшерергә ярдәм итәләр. Тимерче батыр *татара* миченең ут стихиясе белән көрәшә һәм, аны буйсындырып, корычтан кылыч коя. Аждаһа өненә килеп җиткәч, Батыр аның белән дә көрәшә һәм сөйгәнен әсирлектән коткара.

«Татара – Евразия мирасы»ның татар версиясе (премьера 2020 елның 30 августында

булды) шоу-балет формасын хәтерләтә. Бу тамашада авторның төп идеясе музыка, бию, пластика, актерлык осталыгы, сәхнә бизәлеше, ут һәм костюмнар аша җиткерелә. Әмма бу классик балет түгел. Бу заманча модерн бию, ул үзендә акробатика, йога, сугыш сәнгате һәм шәһәрдәге урам биюләре элементларын берләштереп, балет пантомимасыннан баш тарта. Мария һәм Марсель Нуриевлар ачык идеяле образ тудырырга омтылмый, ә тамашачыда ирекле ассоциацияләр тудырырга тырыша.

Шоуның тамаша рәте дә шул максатка йөз тота. Төп мизансценада күкләрдән еланга охшаш ак тасмалар төшә – алар безгә борынгы төрки-монгол халыклары мәдәниятендә очрый торган *дьямала (ямала)* тасмаларын хәтерләтә. Бу тасмаларның исеме борынгы төрки телдәге *шал – «ял»* сүзеннән килеп чыккан. Мондый тасмалар белән корбанга китерелә торган ат ялын бизәгәннәр. Шоуда борынгы төрки цивилизация белән бәйләнеш борынгы руннарны сурәтләү аша да ирешелә. Шул ук вакытта, үз чиратында, еландай боргалана торган тасмалар образы безгә японнарның иероглифлар белән бизәлгән асылмалы төргәкләрен хәтерләтә. Бу традиция Япониягә диварларын ефәк байраклар белән бизәү гадәте булган Кытайдан килгән дип санала.

Шоу-балетның бер-берсенә гашыйк пары тулаем мәхәббәт хисенә бирелә, алар шушы тасмалар шикелле үк өермәле һава агымына буйсына. Геройларның хисләрен динамикада күрсәтү максаты белән, авторлар утлы лаваның динамик образына мөрәҗәгать итә: лава гашыйкларны каплап алып, аларны мәхәббәт хисенең иң югары гәүдәләнеше булган утлы гөлчәчәккә әвереләдерә.

Җирдә идиллия урнашуы турында күкләрдән төшкән зәңгәрсу төргәк хәбәр итә. Алтайның борынгы төркиләре өчен бу күк төсе, тәңре төсе, чыгып килә торган кояшның сакраль төсе. Сүз уңаеннан, әлеге ышанууларның эзләрен әдәбият белгече М. Бакиров татар фольклорында таба, аерым алганда, халык җырында: *«Зәңгәр һава, зәңгәр болыт, / Зәңгәрләтә диңгезне, / Зәңгәр һавалардан эзлим / Бик сагынганда сезне»* [10, 294 б.].

Шоуның икенче мизансценасы гашыйкларның сигез башлы аждаһа белән бәрелешенә нигезләнә. Аждаһа – фарсы мифологиясеннән кергән персонаж. Монда, кызганычка каршы, видеорәттә бер буталчыклык күзгә ташлана. Экранда бер башлы аждаһа пәйда була, ул төркиләрдә дә, японнарда да дошман сыйфатында түгел, ә яклаучы, чикләрне саклаучы буларак кабул ителә. Төрки мифологиядә *сазаган/саруган* мифологик образы бар. Фольклорчы М. Бакиров “Борынгы төрки поэзия” китабында канатлы зур еланны аңлаткан әлеге төрки сүзнең кулланылу өлкәсен системага сала. Галим карашынча, бу сүз әлегә кадәр кумыклар, казакълар *(сазаган),* кыпчаклар *(сазган, саруган, шарукан)*, башкортлар *(һазаган)*, татарлар (*аҗаган*, «елан-яшен-аҗаган) телендә кулланылышта йөри. Татар телендә *саза* тамырының «озын гомерле» дигән мәгънәсе дә бар. Борынгы төркиләр аждаһаның *лулэй* исемен кытайлардан алган. Төркиләрдә бу затның культы хуннар дәверенә үк барып тоташа. Кытай хроникаларына мөрәҗәгать итсәк, Азия хуннарының Лунсы гыйбадәтханәсендә (Аждаһа гыйбадәтханәсе) Күкләргә корбан китерүе турында мәгълүматлар табарга була. С. П. Мелиоранский борынгы күмү йолалары үзенчәлекләрен тасвирлаганда, шуны искәртә: хуннар шаньюйларын ак төстәге елан-аждаһа сурәте төшерелгән кара ефәккә төреп җирләгән. Төрки каганатның хакимнәре Билгә каган белән Күл-тәгин истәлегенә куелган таш стеллаларда *сазаган/ләү* сурәтләре уеп ясалган.

М. Каланкатуйский хәбәр иткәнчә, һун-сувар кабиләләре вәкилләре булган суварлар (Төньяк Кавказ территориясендә яшәгәннәр) муеннарына алтын бизәнгеч әйберләр, канатлы елан сурәте төшерелгән бөти асып йөргәннәр. Көньяк далаларда яшәүче кыпчаклар кылыч, хәнҗәр сапларына, кыннарына елан сурәте төшерә торган булганнар. М. Аджи аларны саклый торган бөти ролен уйнаган дип саный. П. Заринский, А. Халиков канатлы елан-сазаган образы Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорларында дәүләт чикләрен саклаучы илаһи көч булган дип билгелиләр [10, 278-279 б.].

Татарстан Республикасында Алабугага якын урнашкан Шайтан каласыннан канатлы елан-сазаган турындагы тарихи риваятьләр киң таралган (карагыз: «Казан тарихы» (XVI гасыр), Ш. Мөслими «Тәварихе Болгария» (XVIII гасыр), П. Рычковның (XVIII гасыр), Ф. Эрдманның (XIX гасыр) фәнни хезмәтләре). Бу риваятьтә сазаган үзенә табынучы кешеләрнең саклаучысы буларак кабул ителә. Ул тылсымлы көчкә ия: чир-чорлардан дәвалый, алдан күрүчәнлек сәләтенә ия, узып баручы корабларны саклый. Риваять буенча сазаган белән хакимнәр дә хезмәттәшлек итә: Болгар

ханлыгы хакиме мәлик тә, Сөембикә-ханбикә дә. М. Бакиров безнең ата-бабаларыбыз бу затны дошманнарны куркыту өчен сайлап алган, сазаганның күңелен шәфкатьләндереп, аны үзенә хезмәт итәргә мәҗбүр иткән дип саный. Фольклорчы сазаган сурәтенең Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгының гарәп язулы ефәк байракларында да булуы турында кызыклы факт китерә. Боларның барысы да безнең халыкның мәдәни мохитендә *сазаган*ның саклаучы функциясе турында сөйли. Славян халыклары арасында, М. Бакиров фикеренчә, аждаһа культы юк [10, 279-284 б.].

Күренекле татар фольклорчылары күпбашлы елан белән сазаган елан арасындагы аерманың зур булуын искәртә. Төркиләрдә сазаган/ләү – өч дөньяда: күктә, җирдә һәм суда яши ала торган полиморф зат. Декоратив-кулланма сәнгатьтә ул елан гәүдәле, балык койрыклы бер башлы зат (бүре/кош башлы) итеп сурәтләнә. Шул ук вакытта ата-бабаларыбыз бу затны ак/сары төстәге еланнар патшасы итеп тә күзаллаган. Ата-бабаларыбыз фарсы мифологиясеннән кергән берничә башлы еланны дошман күргәннәр, аны аждаһа дип йөрткәннәр. М. Бакиров төркиләрнең *сазаган*га синоним рәвешендә *айдагар* сүзен куллануларын яза [10, 281-282 б.].

Шул рәвешле, видеорәттә логик хата киткән: анда сигез башлы аждаһа урынына тамашачыга бер башлы елан күренеп китә. С. Гаффарованың либреттосын укыганнан соң, без драматургның фарсы мифологиясендәге образны куллануына инандык: *«Аждаһа янына илтер дүрт юлдашың, Хубилай»* .

Либреттоның финалында җирдәге тыныч тормыш идеалы раслана: *«Җиһан безгә яшәү биргән / Муллыкта, тынычлыкта; Аждаһасыз, кылычларсыз / Дөнья ямьле чынлыкта»* (С. Гаффарова). Гомум билгеле булганча, татарларның милли эстетик идеалында геройның физик көченә караганда, аның зирәклегенә һәм тапкырлыгына күбрәк дан җырлау өстенлек итә.

Билгеле фольклор сюжетларын шәрехләүдә драматург та логик хаталар җибәрә. С. Гаффарова үз либреттосында убырлар мотивын куллана: Аждаһа батырның сөйгәнен үбә, һәм кыз үзе дә аждаһага әверелә. Күренә ки, язучы фарсы *аждаһа*сын мишәрләрнең *аздака*сы белән бутый. Фольклорчы Нәкый Исәнбәт үзенең татар мифлары турындагы хезмәтендә күрсәткәнчә, мишәрләр, чувашлар арасында *аздака* исемле явыз рухның ялкын рәвешендә торба аша өйгә кереп, ир-атларны юлдан яздырырга мөмкин дигән ышану яши. *Аздака* матур хатын-кыз кыяфәтенә кереп, ир-атның башын әйләндерә, һәм ул күз алдында корый-кибә башлый. Халык арасында *аздака*ны тотып, аны яхшылап кыйнасаң, ул бу йортка юлны оныта дигән ышану да бар. Буа районы мәгълүматчылары авызыннан Нәкый Исәнбәт *аздака*ның йөкле хатыннарның балаларын корсакта вакытта ук урлый дигән ышану барлыгын да язып ала [11]. Шул рәвешле *аздака*ны *аждаһа* белән бутарга ярамый. Чынлыкта ул аждаһа түгел, ә канечкеч Убырга якын явыз рух.

*Татара* миче образы кергән күренешләрнең сәнгати концепциясе шоуда эпик көчле булуы белән аерылып тора. Төшендә Батыр тылсымлы мичкә сокланып карый, яклаучы стихияләре белән очрашуга үзен рухи яктан көйли. Батырның Һава стихиясе белән очрашуы тәэсирле килеп чыккан. Бу сәхнәгә өстәмә экспрессияне бию генә түгел, сәнгати бизәлеш тә бирә. Батыр эссе җәйге һавада гүя эри, гүя кызыл ноктага әйләнә. Кызыл төс японнарда җылылыкны һәм олы ихтирамны символлаштыра.

Җир образы да эчке тәэсир көченә ия, экспрессияле булып чыккан. Гаҗәеп хореографик һәм тамашалы образлар ярдәмендә, тамашачы лаваның Җирнең өске катламнарына ничек итеп басым ясавын тою мөмкинлегенә ия була. Режиссер сәхнәләрне контраст нигезенә кора. Геройның Ут белән очрашу мизансценасында М. Нуриевның бию хәрәкәтләре ашкынучанлыгы белән аерылып тора, ялкын телләрен хәтерләтә. Су стихиясе белән очрашканда, биюче эчтән үзгәрә: аның хәрәкәтләре акрыная, пластиграк була бара.

Шоуда видеографика әһәмиятле роль уйный. Тамашачы күз алдында гейзерлар су тузанына әйләнә, ә ашкынулы агымнар еланнарның бормалы хәрәкәтләренә охшаш спираль булып формалаша... Батыр сугышканда, бамбук урманнары кызыл төскә буяла. Геройның Аждаһага нәфрәте шул рәвешле метафорик сурәт булып күзаллана. Батырның кылыч йөзе Аждаһаның кайчандыр мәхәббәт идиллиясен сытып киткән тәпиенә охшаш караңгылыкны ярып үтә. Шоу авторлары Аждаһаның портретын тудырганда, тагын бер хата ясаган: алар япон аждаһасының өч тырнаклы булуына игътибар итмәгән.

Финал сәхнәсе романтик буяуларда эшләнгән: гашыйк парга үсемлек бизәкләре төшерелгән яулык ябыла, аның дәвамы булып әйләнә-тирә дә шундый ук бизәкләргә төренә. Бу яулыкның төркиләрнең туй йолаларына аваздашлыгы бар.

Спектакльнең музыкаль бизәлеше сокландыра: шоу вакытында борынгы төрки уен кораллары уйный, татар халык көйләре ятышлы итеп үрелеп китә. Пентатотника борынгы ике мәдәниятнең тагын бер кисешү ноктасын символлаштыра.

2021 елның 16–17 октябрендә Казанда шоуның япон версиясенең премьерасы узды. Шоу башланыр алдыннан, тамашачыларга «Кылыч туганда» документаль фильмы тәкъдим ителде. Ул махсус рәвештә «Самурайлар. Сугыш Сәнгате» (2016) (продюсер Георгий Аистов, куратор Стивен Сигал) күргәзмә проекты өчен төшерелгән. Ул тамашачыларны *татара* корычы җитештерү технологиясе белән таныштыра. Фильмның авторлары *татара* мичен агач белән чагыштыра, агачның яфраклары ялкын телләрен хәтерләтә. «Мичнең куены, аның тирән җиргә күмелгән тамырлары. Корыч тамчылары күз яшьләре кебек быргы кәүсәсе буйлап агып төшә. Ялкын газапларында тамахагани – булачак кылычның җисеме ярала» [12]. Фильмда баш исемнәр сыйфатында декоратив һәм нәфис сынлы сәнгать әсәрләре кулланыла, алар Япония мәдәниятенең үзенчәлеген күзалларга ярдәм итә. Билгеле, фильм мәдәни-агарту бурычын күздә тота, ул тамашачыга *татара* технологиясенең үткәненә һәм бүгенгесенә күз ташларга, самурай кылычы тууның шаһиты булырга мөмкинлек бирә.

Куючы режиссёр Катцуми Сакакура «Татара – Евразия мирасы» проекцияле шоуы сюжетына үзеннән төзәтмәләр кертә. Үзләренең милли традициясе ноктасыннан торып, ул игътибарны мәхәббәткә түгел, ә тәкәбберлек чире йоктырган геройның эчке каршылыгына юнәлтә. Япон шоуының баш герое булып, яуларда җиңүләргә ирешкән самурай тора. Тамашачы күз алдында ул коточкыч аждаһа белән сугышка керә. Аждаһа – геройның күңелен яулаган курку һәм нәфрәт хисләренең гәүдәләнеше булып аңлашыла... Самурай күңеленең караңгы ягын җиңә алырмы? Катцуми Сакакураның герое бер тапкыр да кылычын аждаһадан өстен калдыра алмый, чөнки аждаһа – аның үзенең эгосы, тәкәбберлеге.

Шоу авторлары, тамашачыны герой белән якыннанрак таныштыру өчен, самурайның хатирәләрен яңарта, алар исә тимерче-самурайның мәхәббәт тарихларын үз эченә ала. Алар масаю һәм тәкәбберлектән арынырга ярдәм итә торган рефлексия формасы булып тора һәм тормыш кыйммәтләрен – мәхәббәт, игелеклелек, үз-үзеңне корбан итү, гаилә кыйммәтләре турында искәртә.

Сакакура Кацуминың биючеләре, Миямото Мами, Эйко Иваки, Карин Като самурайның, Аждаһаның, Ут һәм Суның үзенчәлекле образларын тудырган. Кабуки театры традицияләрендә куелган шоуда сюжет әһәмияткә ия түгел, ә биюдән биюгә үзгәреп торган кәеф, халәт мөһим. Биючеләрнең үзенчәлекле костюмнары персонаж турында мәгълүмат биреп кенә калмый, ә бию техникасына да йогынты ясый. Сакакура Кацуми да капма-каршылыкка мөрәҗәгать итә. Япон шоуында ут – сыгылмалы, ә самурай образы – дуэль атмосферасына ярашлы көчле, ашкынучан бию хәрәкәтләре аша бирелә.

Япон шоуында паузалар мөһим роль уйный. Алар биючеләргә тышкы эмоциональлектән арынырга һәм геройларының эчке кичерешләрен тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә.

Бер образдан икенче образга салмак кына күчеш тә тамашачыларның игътибарын үзенә юнәлтә: Ут – Аждаһага, Су – Сөйгән ярга. Шул рәвешле пластика аша тамашачыларда идеаль хатын-кыз сыйфатлары, эпик герой идеалы һәм Яшәешнең күпкырлы булуы турында күзаллау формалаша.

Самурайның үз үзе белән көрәшү сәхнәләре кызыклы килеп чыккан. Экранда күрсәтелгән анимацияле картиналар тамашалы булуы белән аерылып тора һәм хронотопның кысаларын киңәйтүгә хезмәт итә. Музыка белән беррәттән алар спектакльнең темпын да билгели.

Әлеге шоу безнең япон театры турындагы стереотипларны җимерә: Сакакура Кацуми спектаклендә мимика бик аз, битлекләр бөтенләй юк. Хореографиядә традицион булмаган халык биюләре өстенлек итә: япон биючеләрнең биюләре каратэ ритмына нигезләнә, шул ук вакытта үзенә хип-хоп элементларын да алган.

Кызганыч, шоу авторлары VIII гасыр чыганакларында очрый торган «Япония Анналлары» дигән кызыклы материалны искә алмаганнар. Анда *татара* сүзе Япониядә мич исеме генә түгел, ә беренче император Цзинмуның хатыны – Химэ-татара-исузу-но-

химэ-но-микото исемендә дә очравы турында мәгълүмат бар. Иероглифларның мәгънәсенә караганда, принцессаның исеме болай дип шәрехләнә: «илле кыңгырау ханым-туташы, һава чыгара торган капчыкка аягы белән басучы туташ». Хикмәт шунда: япон телендә *татара* сүзе башта фуйго («тимерче өрдергече» мәгънәсендә) дигәнне аңлаткан. Шул ук вакытта япон сүзләренең этимологиясендә император хатынының исеме «аның серле урынына атылган уктан курыккан туташ» дип шәрехләнә [13, 243 б.]. Әйтүләренчә, принцесса Идзумо төбәгенең мөһим алласы Кото-сиро-нуси-но-микотоның кызы булган. Ул японнарның элгәрге мәдәниятендә ике үзәкнең берсе саналган. Бу ноктадан караганда, *татара* сүзенең Япониядә тимер җитештерүче төп районнарның берсеннән чыккан принцессаның исемендә барлыкка килүе үтә дә кызыклы. Толымнарына чулпылар кушып үргән Япон принцессасы образының салмак кына Батырның сөйгәненә әверелүен күрсәтсәләр, аеруча кызыклы булыр иде.

### Нәтиҗәләр

Япониядә сакланып калган *татара* технологиясе, төрки цивилизациянең Кояш чыгышы илендә яшәүчеләр белән элемтәләрен тикшерү өчен, мөһим тарихи чыганак булып тора. Уртак фәнни һәм мәдәни проектлар бүген безгә мәдәният белән якыннанрак танышу һәм ике халык арасындагы дуслыкны ныгыту мөмкинлеге бирә. «Татара – Евразия мирасы» проекцияле шоуы Россия белән Япония мөнәсәбәтләре тарихында моңа кадәр булмаган уникаль проект булып тора. Проекцияле хореографик шоуның япон варианты да, татар варианты да көнбатыш ориентализм рухында эшләнгән. Безнең күз алдында европалы күзлегеннән күренгән Көнчыгыш. «Татара – Евразия мирасы» шоуы ике халыкның милли мәдәнияте нигезләрен тирәнтен өйрәнүдә беренче адымнар булды. Киләчәктә дә әлеге коллективлар безне япон һәм татар мәдәниятләре турындагы күзаллауларның чикләрен киңәйтә торган яңа кызыклы программалары белән сөендерер дип ышанасы килә.

### Йомгаклау

*Татара* мичен ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирас исемлегенә кертү буенча мәдәни проектларның анализы шуны күрсәтте: ике дәүләтнең дә иҗат әһелләре корыч чыныктыруның борынгы технологиясе турындагы сюжетны романтик рухта сурәтләүне өстен күрәләр. Ёсинари Насикори, Сакакура Кацуми, Туфан Имаметдинов, Сөмбел Гаффарованың мәхәббәт тарихлары тимерче геройның инициациясе, үз-үзен җиңүе турындагы сюжет белән тыгыз үрелеп бара. Әгәр дә Ёсинари Насикори «Tatara Samurai» (2016) фильмын төшергәндә, миллилекне шәрехләүдә әсәренең мөмкин кадәр чынбарлыкны чагылдыруына омтылса, Сакакура Кацуми белән Туфан Имаметдинов стильләштерүгә таба йөз тота. Проекцияле шоуның татарча вариантына әкияти-фантастик гомумиләштерү хас булса, япон вариантының символик формасы мифлаштыру белән аерылып тора.

**Рәхмәт сүзләре**: Автор ТР ФАнең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтына һәм шәхсән директор урынбасары Марат Мингали улы Гыйбатдиновка, мәкаләне язганда, консультацияләр белән ярдәм иткән өлкән фәнни хезмәткәр Лариса Рафаэль кызы Усмановага үз рәхмәтләрен белдерә. Гыйльми хезмәтне язу өчен кирәкле видеоматериаллар белән тәэмин иткән «Сакура» татар-япон мәдәни-мәгълүмати үзәгенең җитәкчесе Асия Йосыф кызы Садыйкова, режиссер Туфан Имаметдинов аерым рәхмәтләргә лаек.

#### Әдәбият

1. Культурные, экономические, технологические контакты и взаимодействие Японии и Татарского мира: история и современность. Сборник материалов Международной научной конференции, посвященной 80-летию мечети в г. Кобе (Токио-Мацуэ, 19, 23 октября 2015 г.) / Под ред. М. М. Гибатдинова, Л. Р. Усмановой. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. 160 с.
2. Культурные, экономические, технологические контакты и взаимодействие Японии и Татарского мира: история и современность: сборник научных трудов. Вып. II. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2018. 256 с.
3. Культурные, экономические, технологические контакты и взаимодействие Японии и Татарского мира: история и современность: сборник научных трудов. Вып. II. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2021. 272 с.
4. *Ма Мин Да.* Историческое исследование китайско-японско-корейских обменов в области искусства фехтования мечом. Пекин: Чжунхуа шуцзюй, Интернет-издание, 2007. 130 с.
5. *Курбатов В. А.* « Татар»ские топонимы в Японии // Золотоордынская цивилизация. 2016. № 9. С. 12–15.
6. *Киддер Д.* Япония до буддизма. М.: Центрполиграф, 2003. 286 с.

7. *Курбатов В. А.* Россия до Руси. По следам индоевропейцев. М.: ООО «Буки Веди», 2013. 528 с.
8. *Хакимов Р.* Как возникла Великая Татария и чем она стала. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2018. 197 с.
9. *Гаффарова С.* Татара уты // М. Хәбетдинова шәхси архивы. Кульъязма. 5 б.
10. *Бакиров М.* Древнетюркская поэзия. Казань: Татар кн. изд-во, 2014. 390 с.
11. *Исәнбәт Н.* Татар мифлары. Кульъязма // Н. Исәнбәт шәхси архивы. Кульъязма. 151 б.
12. Самураи. Искусство Войны. URL: http://isamurai.ru/ (дата обращения: 02.03.2022).
13. Нихон сіеки: Анналы Японии: в 2 т. Т. 1. СПб: Гиперион, 1997. 494 с.

# ХУДОЖЕСТВЕННАЯ КОНЦЕПЦИЯ ОБРАЗА *ТАТАРА* В СОВРЕМЕННОМ РОССИЙСКОМ И ЯПОНСКОМ КИНЕМАТОГРАФЕ И ПРОЕКЦИОННОМ ХОРЕОГРАФИЧЕСКОМ ШОУ «ТАТАРА – НАСЛЕДИЕ ЕВРАЗИИ»

**Милеуша Мухаметзяновна Хабутдинова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
mileuscha@mail.ru.

Объектом исследования в статье послужили художественный фильм «Tatara Samurai» («Кузнец-самурай», режиссер Ёсинари Насикори, 2016), документальный фильм «Рождение меча» (выставочный проект «Самураи. Искусство Войны» (2016) – продюсер Георгий Аистов, куратор Стивен Сигал) и проекционное хореографическое шоу «Татара – наследие Евразии» (режиссер-постановщик Туфан Имамутдинов (2020), режиссер-постановщик Катцуми Сакакура (2021)). Предмет данного исследования – образы кузнеца-самурая и печи *татара.* В статье систематизированы сведения о степени изученности уникальной технологии *татара* и одноименной печи, сохранившейся в Японии, в свете тюркско-японских контактов. Выявлена специфика художественной интерпретации этой темы современными деятелями культуры Японии и Республики Татарстан. Доказано, что Ёсинари Насикори, Сакакура Кацуми, Туфан Имамутдинов, Сюмбюль Гаффарова разрабатывают сюжет о противостоянии эпического героя с драконом во имя спасения возлюбленной в романтическом ключе. Главным становится сюжет об инициации. Любовный сюжет играет вспомогательную роль. Японские и татарские сценаристы концентрируют внимание на особенностях внутреннего конфликта главного героя с самим собой. Если режиссер Ёсинари Насикори стремится в трактовке национального к достоверности, то режиссеры-постановщики Сакакура Кацуми, Туфан Имамутдинов тяготеют к стилизации. Татарский вариант проекционного шоу тяготеет по форме к сказочно-фантастической обобщенности, тогда как символическая форма японского варианта, скорее, к мифологичности. Документальный фильм «Рождение меча» носит просветительский характер.

**Ключевые слова:** Япония, Республика Татарстан, культурные контакты, Ёсинари Насикори, Сакакура Кацуми, Туфан Имамутдинов, печь *татара,* кузнец-самурай